**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 апрелендәге 1138 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 мартындагы 1219 номерлы карары белән расланган «Яңа Порт» гидротехник корылмасы (1 нче этап)» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Төзелеш кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары нигезендә, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2025 елга муниципаль биремен исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 мартындагы

1219 номерлы карары белән расланган «Яңа Порт» гидротехник корылмасы (1 нче этап)» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 21 маендагы 1566 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карарның кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, гидротехник корылма линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен территория чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре

Башкарма комитетының
2026 елның 10 апрелендәге
1138 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 мартындагы 1219 номерлы карары белән расланган «Яңа Порт» гидротехник корылмасы (1 нче этап)» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Өченче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«II. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чигенең һәм гидротехник корылма төзүгә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чигенең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмәләр».

2. Дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чигенең характерлы нокталар координатлары исемлеге (2 номерлы кушымта) һәм гидротехник корылма төзүгә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чигенең характерлы нокталары координаталары исемлеге (3 номерлы кушымта) хезмәт урынында файдалана торган документ булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

3. I «Территорияне планлаштыру проекты сызымы фрагменты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең сызымы» бүлегенең шартлы билгеләрендә «планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре (гидротехник корылма чиге)» сүзләрен «планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре» сүзләренә алыштырырга.

4. «Территорияне планлаштыру проекты сызымы фрагменты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең сызымы»н әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

5. II «Линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмә» бүлегендә:

5.1. «Урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектының исеме һәм билгеләнеше» 2.1 пунктның 15 абзацындагы «11,93» саннарын «11,83» саннарына алыштырырга;

5.2. «Урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектының төп характеристикалары» 2.2 пунктында:

5.2.1. 1 абзацтагы «2550» саннарын «2559,49» саннарына алыштырырга;

5.2.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Капиталь төзелеш объекты зонасына – гидротехник корылмага һәм гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чигенә туры килә торган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары тартып алынырга тиеш»;

5.3. «Мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге» 2.4 пунктын төшереп калдырырга;


5.4. линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләп бирергә;

5.5. әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендә гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген өстәргә.

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 29 мартындагы 1219 номерлы
карары белән расланган «Яңа Порт»
гидротехник корылмасы (1 нче этап)»
җирле әһәмияттәге линия объекты
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә 1 номерлы
кушымта


## I. Территорияне планлаштыру проекты сызымы фрагменты. График өлеш. Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең сызымы

**1 бит**




| **ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:** | |
|---|---|
| | - планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| | - гидротехник корылманың линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләре |
| | - гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чиге |
| | - гидротехник корылманың (кордон сызымы) беренче шпунт рәте күчәре 55 билгесендә |
| | - гидротехник корылманың икенче шпунт рәте күчәре 58 билгесендә |
| ○1 | - гидротехник корылма линия объектын план бюуенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| ○1 | - гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| | - гамәлдәге кызыл линия |
| красная линия | - гамәлдән чыгарыла торган кызыл линия |

## 2 бит




| | |
|---|---|
| **ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:** | |
| | - планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| | - гидротехник корылманың линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләре |
| | - гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чиге |
| | - гидротехник корылманың (кордон сызымы) беренче шпунт рәте күчәре 55 билгесендә |
| | - гидротехник корылманың икенче шпунт рәте күчәре 58 билгесендә |
| 1 | - гидротехник корылма линия объектын план бюуенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| 1 | - гидротехник корылма төзелешенә бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле территория чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| | - гамәлдәге кызыл линия |
| красная линия | - гамәлдән чыгарыла торган кызыл линия |